Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАРЫ

2014 елның 21 феврале 52№

Әлки муниципаль районының 2013 елда социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2014 елга бурычлары турында

Әлки муниципаль районы Башлыгының 2013 елда Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2014 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, депутатлар, Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге 2013 елда халык мәнфәгатьләрендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Россия Федерациясе һәм “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән компетенцияләр һәм вәкаләтләр нигезендә гамәлгә ашырылды, дип билгелиләр. Җирле үзидарәнең вәкиллекле һәм башкарма органнары эшчәнлегенең беренче чираттагы бурычлары арасында хуҗалык эшчәнлегенең барлык юнәлешләре буенча муниципаль берәмлекне үстерү программаларын кабул итү һәм гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан район Советы карарларын һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен контрольдә истә тотып Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

**1.** Район башлыгының 2013 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2014 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга.

**2.** Әлки муниципаль районы Советы депутатларына 2013 елда Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2014 елга бурычлар турында отчетны үз округларында сайлаучылар игътибарына җиткерергә.

**3.** Әлки муниципаль районы Советы Аппаратына:

- хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә;
- кабул ителгән муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору функциясен көчәйтергә.

**4.** Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына (Никошин А.Ф.) тәкъдим итәргә:

- хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү өчен, чаралар планын эшләргә һәм депутатларга 2014 елның 1 апреленә кадәр мәгълүмат бирергә;
- районда икътисад һәм социаль өлкә секторларын үстерүне тәэмин итү чараларын күрергә;
- районда кече һәм урта бизнесны үстерүне тәэмин итәргә, шуның белән урта сыйныф өлешен арттырырга;
- шәхси торак төзелеше темпларын саклап калу чараларын күрергә;
- күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау программасын сыйфатлы гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

- 2013-2015 елларга Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программасының төп бүлекләрен үтәүне тәэмин итәргә, аның максаты икътисадны тотрыклы, динамик үстерү һәм район халкы өчен имин мохит булдыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын яхшыртудан гыйбарәт;

- җәйге чорда балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерү ялын һәм мәшгульлеген оештырырга;

- хокук бозуларны профилактикалау буенча максатчан эш алып барырга;

-2014 елга район бюджетының керем өлешен үтәүне тәэмин итәргә.

**5.** Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләре Советлары утырышларында Әлки муниципаль районы Башлыгының хисабы буенча фикер алышырга һәм хисап докладында әйтелгән искәрмәләрдән чыгып, чаралар планын эшләргә;

- территорияләрне комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- яшьләрне авылда калдыру өчен кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләреннән мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга;

- районның торак пунктларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә, гаилә фермалары төзү программаларын гамәлгә ашыруга аерым игътибар бирергә;

- хокук саклау органнары белән берлектә иҗтимагый иминлек дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм абруен ышанычлы яклауны, җирле потенциалны максималь файдаланып, хосусый дәүләт һәм муниципаль милекне тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга;

- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту, экологик иминлекне тәэмин итү чараларын дәвам итәргә;

Якташлык институты мөмкинлекләреннән киңрәк файдаланырга.

**6.** Әлки муниципаль районы Бшлыгының 2013 елда Әлки муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2014 елга бурычлар турындагы хисабын«Әлки хәбәрләре» («Алькеевские вести») район газетасында һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**7.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: Ф.М. Дәүләтшин